Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КИЛДЕБӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422071, Татарстан Республикасы
Килдебәк авылы, Кооператив
урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

Kilb.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
01.07.2021

КАРАР
№ 43

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитеты
тарафыннан расланган 07.06.2021 елгы № 37
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Килдебәк авыл җирлеге муниципаль торак
фондының социаль наем шартнамәләре һәм
муниципаль торак фондыннан торак урыннарны
яллаучылар өчен торак урыннардан (наемга түләү)
файдаланган өчен түләүне исәпләү тәртибе турындагы
Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Төзелеш Министрлыгының 19.06.2017 елгы 892/пр номерлы боерыгы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номеры белән расланган «Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында» боерыгына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннары наемга алучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга түләү өчен) күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 07.06.2021 елгы 37 номеры белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл

җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннарыннан (наемга өчен) файдаланган өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы Нигезләмә” карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләү коэффициенты торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) билгеләнгән вакытка – 0,3 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен түләүнең ташламалы критерийлары билгеләнә:

- 3 һәм аннан да күбрәк баладан торган күп балалы гаиләләр өчен-0,15;
- пенсионерлар өчен (55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшькә җиткән ир-атлар) -0,15;
- инвалидлар өчен – 0,15.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге рәсми сайтында hhttp://saby.tatarstan.ru/kildebiak адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Килдебәк авыл
җирлеге башлыгы: Н.Н.Заһидуллин